# "ТӨП БУРЫЧ – ХАЛЫКНЫҢ СОЦИАЛЬ ИМИНЛЕГЕ"

(⇨ Башы 1нче биттә).

— Ишембай шәһәре республиканың нәкъ уртасында урнашкан. Ул өч шәһәр арасында урнашкан һәм ул территориядә ярты миллион чамасы кеше яши. Бу — Русиянең сәнәгать һәм газ химиясе үзәге. "Газпром нефтехим Салават" нәкъ менә шунда урнашкан. Без "Газпром" белән хәзер табигый газны эшкәртеп, этилен һәм пропилен җитештерү комплексы проекты өстендә актив эшлибез, хәзерге вакытта бу өлкәдә беренче адымнар ясыйбыз. Һәм махсус икътисади зонаны формалаштыру, киләчәктә индустриаль парк булдыру, әлбәттә, бу төбәктә тормышны яхшыртачак, — диде Радий Хәбиров.

Русия Хөкүмәте Рәисе Дмитрий Медведев билгеләп үткәнчә, бу өлкәдә яңа эш урыннары булдыру, инвестицияләр җәлеп итү, хезмәт хакы һәм социаль объектлар үсешенә йөз тотып карарлар кабул итәргә кирәк.

— Әгәр ирекле икътисади зона булдыру идеясе барлык критерийларга да җавап бирсә, мин бу башлангычны хуплаячакмын. Шуңа күрә тәкъдимнәр әзерләгез, — диде Дмитрий Медведев.

Шул ук көнне Мәскәүдә Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров Русиянең авыл хуҗалыгы министры Дмитрий Патрушев белән очрашты. Аграрийларга дәүләт ярдәме мәсьәләләре һәм төбәкнең экспорт потенциалын үстерү перспективалары турында фикер алышу булды.

Очрашу барышында билгеләп үтелгәнчә, быел республика авыл хуҗалыгына дәүләт ярдәме өчен 2,71 миллиард сум федераль бюджет акчалары каралган. 27 июньгә әлеге сумманың 45,2 проценты күчерелгән, бу ил буенча уртача күрсәткечкә туры килә.

Төбәктә агросәнәгать комплексында инвестиция проектларына ярдәм итүгә зур игътибар бирелә. Бу авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүнең үсешен активлаштырырга һәм республиканың экспорт потенциалын арттырырга мөмкинлек бирә. Хәзерге вакытта Башкортстанда 559 инвестиция проекты гамәлгә ашырыла, аларга салынган субсидияләрнең гомум күләме 1,6 миллиард сум.

Дәүләт ягыннан ярдәм чаралары агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлауны арттыруны дәртләндерү. Былтыр ул, алдагы елдагы белән чагыштырганда, ике тапкыр арткан. Федераль таможня хезмәтенең 23 июньгә оператив мәгълүматлары буенча, экспорт 33,1 миллион доллар тәшкил иткән. Төбәктән чит илләргә озатылучы төп товарлар булып бодай, көнбагыш мае һәм арыш тора. Шул ук вакытта Башкортстан БДБ илләре белән генә түгел, Латвия, Иран, Төркия белән дә сәүдә итә. Очрашуда авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү һәм агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау эшен көчәйтергә кирәклеге билгеләнде.

Яклар, шулай ук, апрельдә төшкән кырау һәм үсемлекләр авыруларына бәйле рәвештә төбәк авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә күргән зыянны компенсацияләү мәсьәләсе буенча фикер алышты. Бу максатларга федераль бюджеттан 2,5 миллиард сум каралган. Акча аграрийларга Русия Хөкүмәтенең тиешле карарыннан соң биреләчәк.

**Фәнүз ХӘБИБУЛЛИН.**

*Сайлаулар-2019*

# "Һәр кандидатны җитди тикшерәбез"

**Республика Башлыгы вазыйфасына 11 кандидат күрсәтелде. Аларны теркәү ничек башкарыла? Хокукый база аларны ничек яклый? Шушы һәм башка сораулар белән без республика Үзәк сайлау комиссиясе секретаре Марина ДОЛМАТОВАга мөрәҗәгать иттек.**

**— Марина Борисовна, республика Башлыгы вазыйфасына канидатлар теркәү ни рәвешле башкарыла?**

— Сайлауларга кандидатлар теркәү — сайлау процессының бер этабы ул. Бу сайлау комиссиясенең кандидатны рәсми теркәвен аңлата һәм аны сайлау бюллетеньнәренә кертүнең шарты булып тора. Кандидатны теркәгәннән соң сайлау комиссиясе үз теләге белән аны теркәү карарын кире кага алмый. Моның өчен аңа судка мөрәҗәгать итәргә кирәк булачак. Атап әйткәндә, теркәлгән кандидатның эшчәнлеге гарантияләнгән була.

**— Гадәттә, теркәлгән кандидат халык белән очраша һәм башка чараларда катнаша. Бу күп көч һәм вакыт таләп итә. Моның өчен алар эш урыннарын калдырып китәргә тиешме?**

— Теркәлгән кандидат, гариза язып, эш урынын калдырып тора ала, әмма аның бу вакыты мотлак сайлауларга әзерлек өчен файдаланылырга тиеш. Шул ук вакытта, теркәлгән кандидатны бу вакытта җитәкчесе эшеннән бушата яисә башка вазыйфага күчерә алмый. Шулай ук, кандидат, прокурор ризалыгыннан тыш, нindидер җаваплылыкка тарттырылмый.

**— Сайлауларда катнашу өчен кандидат республиканың Үзәк сайлау комиссиясенә нинди документлар тапшырырга тиеш?**

— Тәү башлап, ул муниципаль берәмлекләрдәге депутатлардан үз кандидатурасын хуплау өчен имзалар җыярга тиеш. Шулай ук, ул бу депутатларның исемлеген дә күрсәтергә бурычлы. Әгәр дә белешмәдәге мәгълүмат үзгәрсә, ул аны да күрсәтә. Кандидат беренче финанс отчеты һәм үзенең чит ил банкларында акча яисә башка мөлкәте юклыгы турында да мәгълүмат бирергә бурычлы. Шулай ук, ул Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен 3 кандидатура турында мәгълүмат тапшырыла, аларны тәкъдим иткән кандидат сайланган очракта, әлеге өчәүнең берсенә Федерация Советы вәкаләтләре тапшырылачак.

**— Марина Борисовна, кандидатлар бу документларны кайчан тапшырырга тиеш? Нинди очракта кандидатларның теркәү турындагы гаризасы кире кагыла?**

— Кандидатлар бу документларны 11 июльгә кадәр урындагы вакыт белән 18 сәгатькә кадәр тапшырырга тиеш. Республиканың Үзәк сайлау комиссиясе аларны 10 көн эчендә тикшерә. Шул ук вакытта, Үзәк сайлау комиссиясе республика буенча Эчке эшләр министрлыгына, миграция һәм салым хезмәтенә, уку йортларына мөрәҗәгать итә. Әгәр дә кандидат күрсәткән мәгълүмат чынбарлыкка туры килмәсә, Комиссия моны киңкүләм мәгълүмат чаралары аша җиткерә.

Әлеге тикшерүләр тәмамлангач, Үзәк сайлау комиссиясе кандидатны теркәү яисә теркәмәү турында карар кабул итә. Бу агымдагы елның 20 июленә кадәр башкарылырга тиеш. Теркәлгән кандидатка аның теркәлүе турында таныклык тапшырыла.

**— Әңгәмә өчен рәхмәт.**

**Гөлия ГӘРӘЕВА әңгәмәләште.**

*Икътисади күзәтү*

# Дәүләт контроле көчәйтелә

## Президент Владимир Путин төбәкләргә юллар төзелешенә һәм сыйфатына бәйле яңа бурычлар йөкләде

**Билгеле булуынча, узган атнада Русия Дәүләт Советының гомум билгеләнештәге автомобиль юллары челтәрен үстерүгә һәм юл хәрәкәте хәвефсезлеген тәэмин итүгә багышланган утырышы булды. Анда Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров та катнашты.**




Әлеге зур җыелышта юл төзелешенең нәтиҗәлелеге, юлларны ремонтлау һәм хезмәтләндерү сыйфаты, юл хәрәкәтен оештыруны яхшыртуга кагылышлы көнүзәк проблемалар тикшерелде.

Русия Президенты Владимир Путин белдерүенчә, илдә югары сыйфатлы юллар күп түгел. Сыйфатлы юллар төзелешендә уңай якка үзгәреш федераль трассаларда гына күренә. Дөрес, беренче категорияле юлларның гомум озынлыгы соңгы дүрт елда 2 423 чакрымга артты. Тулысынча норматив таләпләргә туры килүче трассалар 83 процент тәшкил итә. Төбәк әһәмиятендәгеләрдә юл катламы югары сыйфатлы булган трасса өлеше 50 проценттан да ким тәшкил итә.

Хәбәр ителүенчә, Русия Хөкүмәте алдагы биш елда юлларны ремонтлауга һәм хәрәкәт хәвефсезлеген тәэмин итүгә 5 триллион сум акча тотынырга җыена. Русия Президенты Владимир Путинның май указларына ярашлы кабул ителгән "Хәвефсез һәм сыйфатлы автомобиль юллары" гомумдәүләт проектын финанслау шул суммага төшәчәк. Әлеге проект кысаларында Башкортстанга федераль бюджеттан юллар төзелешенә һәм хәвефсезлекне тәэмин итүгә 2024 елга кадәр 34,5 миллиард сум акча бүлү каралган.

– Юл хуҗалыгында системалы үзгәрешләргә ирешү өчен һәр төбәккә тиз арада тиешле программа эшләргә һәм кабул итәргә кирәк. Ул 2024 елга кадәр исәпләнгән реаль программа булырга тиеш, – диде Владимир Путин Дәүләт Советы утырышында. – Бу юл төзүчеләргә кыйммәт техника сатып алырга, төзелеш материалларын тупларга, кадрларга һәм яңа тех-нологияләргә акча тотыну мөмкинлеге бирәчәк.

Владимир Путин, шулай ук, юл төзелеше эшләрен финанслау, инновацион карарларны гамәлгә кертү өчен административ каршылыкларны киметү, трассаларны яктырту, авыр йөк машиналары йөрешен көйләү темаларына тукталды, юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү буенча күрелүче чараларның нәтиҗәлелеге мәсьәләсен күтәрде.

Әйтергә кирәк, Президент билгеләгән "системалы үзгәрешләргә ирешү өчен" Башкортстанда тиешле база бар һәм бу юнәлештә эзмә-эзлекле эш алып барыла. Мәсәлән, Башкортстанның Юл фонды соңгы чорда гына да 3 миллиард сумга арттырылды.

Республикадагы юлларның гомум озынлыгы 47 700 километр тәшкил итә. Автотранспорт белән йөк ташу буенча Башкортстан илдә 19нчы урында булса, пассажирлар йөртү буенча – 8нче. Узган елда республикада 70 километр яңа юллар файдалануга тапшырылды, мең километрдан артыгы норматив таләпләргә яраклаштырырлык итеп төзекләндерелде. Агымдагы елда төбәк һәм муниципалитетлар дәрәҗәсендәге юлларны ремонтлауга 5,8 миллиард сум сарыф итү планлаштырылган. Уфаны көнчыгышка таба кисеп чыгучы юл төзелеше, шулай ук, әһәмиятле башка проектлар гамәлгә кертелә башлады.

Республикада "Сыйфатлы һәм хәвефсез юллар" гомумдәүләт проекты кысаларында юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны фотовидеотеркәү комплекслары урнаштыру дәвам итә. Алар казна акчасына сатып алына. 60 комплекс 1 июльдән үк эшли башлады. Гомумән алганда, быел төбәк юлларында 280гә якын шундый комплекс барлыкка киләчәк. Мондый комплекслар юлларда тәртип урнаштырырга, тиешле тизлекне арттырып йөрергә яратучы водительләрне искәртергә, Юл фондын (штрафлар исәбенә) тулыландырырга ярдәм итәчәк. Мәсәлән, агымдагы елда штрафлар 1,6 миллиард сум чамасы булачак дип фаразлана. Моңа кадәр юл кагыйдәсе бозган өчен түләтелгән штрафлар турыдан-туры бюджетка киткән булса, агымдагы елдан алар Юл фондына күчерелә.

**Идрис СӘЕТГАЛИЕВ.**

Издательство "Кызыл таң" — филиал ГУП РБ Издательский дом "Республика Башкортостан". Учредители республиканской общественно-политической газеты "Кызыл таң" — Государственное собрание — Курултай, Правительство Республики Башкортостан. Издается с 1 марта 1918 года. Выходит во вторник, четверг и пятницу на татарском языке.

**Баш мөхәррир**
**Фаил Камил улы ФӘТХЕТДИНОВ.**
**Мөхәрририят:**
**Илдар Фазлетдинов** (җаваплы секретарь), **Фәнис Гәрәев, Резеда Нуртдинова, Рәфис Сәяхов**, **Олег Төхвәтуллин** (баш мөхәррир урынбасарлары), **Фәрит Фаткуллин.**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
450079, БР, Уфа, Октябрьнең 50 еллыгы урамы,13, 6нчы кат.
Адрес редакции и издателя:
450079, РБ, Уфа,
ул. 50-летия Октября,13,
6-й этаж.
kyzyltan@mail.ru

Гәзит Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәттә 2008 елның 24 сентябрендә теркәлде.
Теркәлү саны — ПИ №ФС 77-33268
Күләме – 4 басма табак
Гомум тиражы —5337 данә
**Заказ № 1076.**

Гәзит "Кызыл таң" нәшриятының компьютер цехында җыелды һәм Нефтекама матбугат йорты типографиясендә басылды:
452680, БР, Нефтекама шәһәре,
Березовка шоссесы, 4А,
тел. (8-34783) 7-07-57.
Газета отпечатана в типографии Нефтекамского дома печати.
452680, РБ, г. Нефтекамск,
Березовское шоссе,4А,
тел. (8-34783) 7-07-57.

**Телефоннар:**

| | |
|---|---|
| Кабул итү бүлмәсе — | 272-13-61 |
| баш мөхәррир урынбасарлары — | 272-97-71; 273-50-56 |
| җаваплы секретарь — | 272-74-05 |
| Бүлекләр: | |
| сәясәт, икътисад һәм милли проблемалар — | 272-58-40 |
| әдәбият һәм сәнгать — | 272-35-22 |
| авыл тормышы һәм үз хәбәрчеләр челтәре — | 273-46-19 |
| яңалыклар — | 272-75-68 |
| хатлар һәм социаль мәсьәләләр — | 272-82-07 |
| рәссам — | 272-75-21 |
| реклама — | 272-62-27 |
| маркетинг — | 272-35-70 |
| бухгалтерия — | 273-43-43 |
| тәрҗемәчеләр — | 272-74-52 |
| "Әллүки" журналы — | 272-62-19 |
| "Тулпар" журналы — | 272-67-48 |

Факс — 273-88-01, 272-62-27

Үз хәбәрчеләребез:

| | |
|---|---|
| Октябрьский, Бүздәк, Әлшәй, Благовар | 8-937-30-24-087 |
| Борай, Кушнаренко, Дүртөйле | 8-917-80-37-750 |
| Илеш, Бакалы, Шаран | 8-937-49-35-735 |

*Гәзит чыгышларына карата килгән хатларга җавап бирелми, кулъязмалар, фотолар, рәсемнәр рецензияләнми, кире кайтарылмый. Редакциянең консультация бүлеге юк. Авторлар фикеренең редакциянеке белән туры килүе зарури түгел.*

*Реклама һәм игъланнарның эчтәлеге өчен реклама бирүчеләр җаваплы.*

"Кызыл таң"ның индексы:
атнага өч тапкыр басылганынык — П2760
атнага бер тапкыр — П3408
"Әллүки" журналы — П2712
"Тулпар" журналы — П2715

Безнең дәүләт банкы реквизитлары:
Издательство "Кызыл тан"
филиал ГУП РБ Издательский дом
"Республика Башкортостан"
БАШКИРСКИЙ РФ АО
"РОССЕЛЬХОЗБАНК"
р/с 40602810862000000102
к/с 30101810200000000934
БИК 048073934
ИНН 0278066967
КПП 027843006
ОКПО 31226910
ОКВЭД — 58.13.1
Дежур: Г. МӨГАЛЛИМОВА,
З. ИБРАҺИМОВА.

© "Кызыл таң" № 77 (25381). 12+

*Оператив киңәшмә*

# "Мин сезнең әкиятегезне күп тыңладым!"

## Республика җитәкчесе Радий Хәбиров подъездлар ремонтлаудагы сүлпәнлекне бетерү бурычын куйды

**Оператив киңәшмә барышында республика Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров Торатауда үткән сабантуйны оештыручыларга рәхмәт белдерде. 50 мең кеше җыелган чарада бер генә җәмәгать тәртибен бозу очрагы да теркәлмәгән. Республика җитәкчесе, шулай ук, бу бәйрәмнең ел саен үткәреләчәген ассызыклады.**

Ике ел эчендә республикада 7,5 мең урынлык 53 мәктәпкәчә балалар учреждениесе сафка кертеләчәк. Бу хакта Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт комитеты рәисе вазыйфасын башкаручы Марат Әхмәдуллин белдерде.

Әлеге вакытта 12 балалар бакчасы иске бинада урнашкан. Быел ук 29 объект эшкә кушылачак. Шуларның икесе — Уфада, тагы да Күмертау, Бәләбәй, Белорет, Борай, Зианчура, Краснокама, Күгәрчен, Мәчетле, Салават, Чакмагыш, Стәрлетамак, Уфа районнарында. Киләсе елда исә 3890 урынлык 24 балалар бакчасы төзеләчәк.

Ләкин бу объектлар төзелгәннән соң да балалар бакчасына мохтаҗлык калачак. Өстәмә рәвештә 169 мәгариф объекты, шул исәптән 65 балалар бакчасы, төзергә кирәк булачак. Әле республикада балалар бакчасына путевка алырга 88 мең сабый чиратта тора, шуларның 25 меңе — ясле яшендә.

Башкортстанда подъездлар ремонтлау программасы кысаларында күпфатирлы йортлардагы 4000 подъезд ремонтланырга тиеш. Бу хакта Хөкүмәт Премьер-министры урынбасары, республиканың торак-коммуналь хуҗалык министры вазыйфасын башкаручы Борис Беляев белдерде. Әлеге вакытка 1123 подъезд ремотланырга тиеш булса да, бу эшләр 620сендә генә башкарылган. Радий Хәбировка графиктан бу кадәр артта калу ошамады, ул чиновникның чыгышын тәнкыйть утына тотты.

— Программаны башлаганда ук җитешсезлекләр күп булды, мин моны беркайчан да онытмаячакмын. Графиктан ике тапкыр артта каласыз, бу — гадәттән тыш хәл, дип исәплим. Мин сезнең әкиятегезне күп тыңладым. Ни өчен графикны үтәмисез? Төбәк операторы ни белән шөгыльләнә? Аның ничә урынбасары бар? Җиде? Хезмәт хаклары күпме? 300 миллион сум авансka акча бүлгәннәр. Бу акчаны бүлгән кешенең исем-фамилиясен әйтегез. Урынбасарларын куып таратыгыз, алар монда утыручылардан да күбрәк хезмәт хакы ала, — диде Радий Хәбиров.

*— Программаны башлаганда ук җитешсезлекләр күп булды, мин моны беркайчан да онытмаячакмын. Графиктан ике тапкыр артта каласыз, бу — гадәттән тыш хәл, дип исәплим. Мин сезнең әкиятегезне күп тыңладым. Ни өчен графикны үтәмисез?*

Республика җитәкчесе подъездларда ремонтның сыйфатсыз үткәрелүе турында шикаятьләр килүен хәбәр итте. Югыйсә, программаны гамәлгә ашыруга җитәрлек күләмдә акча бүленгән.

Ул подъездлардагы да, юллардагы чокыр-чакырлар ремонтларын да үзе даими тикшереп йөри. Һәм бик күп җитешсезлекләрне күрә. Әлеге киңәшмәдә Радий Хәбиров Уфаның Октябрь районы башлыгы эше белән канәгатьсезлеген белдерде. Атап әйткәндә, Сипайловода ихаталарның тәртипсез хәлдә булуын бәян итте. Уфа хакимияте башлыгы Өлфәт Мостафинга ул, башкала районнары башлыклары белән Учалыга яисә Ишембайга барып, анда тәртип урнаштыру буенча алдынгы тәҗрибәне карап кайтырга тәкъдим итте. Учалыда чүп-чар табып булмый, ә Сипайловода бөтен җирдә төзелеш калдыклары аунап ята, билгә кадәр үлән үсеп утыра...

— Ике ай элек мин бу хакта кисәткән идем инде. Ишетүче юк. Бер айдан соң тагын барып караячакмын. Шушы вакыт эчендә тәртип урнаштырыгыз. Ә Октябрь районы хакимияте башлыгына әйтегез: мин аның белән эшләмәячәкмен, хөкүмәт учреждениеләрендә йөрмәсен дә, — диде Радий Хәбиров.

Республикада 24 укучы мотлак булган ике фәннән БДИ тапшырмаган өчен аттестат алмаячак. Былтыр андыйларның саны 9 гына булган. Радий Фәрит улы аларны күз уңыннан яздырмаска, ярдәм итәргә кушты.

Быел барлыгы 19787 укучы Бердәм дәүләт имтиханы тапшырган. Шушы чорда ун кеше төрле сәбәпләр белән имтиханнан чыгарып җибәрелгән. Имтиханны 100 баллга тапшыручылар саны — 109. Шуларның 68е укуларын республикадан читтә — Мәскәүдә, Санкт-Петербургта һәм Казанда дәвам итәргә ниятли.

Оператив киңәшмәдә, шулай ук, ихаталарда балалар мәйданчыклары торышы, торак пунктларда сөт кухнялары эшен оештыру һәм продукциягә алдан заказ бирү өчен мобиль кушымта кертү турында да сүз булды.

**Резеда ГАЛИКӘЕВА.**